Мөслим районы газетасы
Татарстан Республикасы
Җомга
№ 12 (11361)
**19 февраль** 2021 ел
Газета 1931 елдан бирле чыга 16+

# Авыл утлары

**БЕЗ – МӨСЛИМЛЕЛӘР!**

**Сельские огни**

Район яңалыклары – безнең сайтта **www.muslumirc.ru** һәм социаль челтәрләрдә

# Әсгать Сәфәров: “Шәһәрләр дә көнләшерлек”

Район Советы сессиясендә районның халык хуҗалыгы тармакларының узган елдагы эшчәнлегенә йомгак ясалып, киләчәккә бурычлар билгеләнде.



Андрей Митрофанов фотосы.

Районыбыз йөзе

**Әлфинур Ногманова**

**IV чакырылыш Мөслим муниципаль район Советының V сессиясе эшендә Татарстан Республикасының Президент аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, республика буенча баш медик-социаль экспертиза җитәкчесе Ригель Низамов, ТР Дәүләт Советы депутаты Альберт Хәбибуллин, Президент аппаратының, ведомстволарның җаваплы хезмәткәрләре, инвесторлар, авыл хуҗалыгы формированиеләре һәм оешма-предприятие җитәкчеләре катнашты.**

Сессия утырышының көн тәртибе буенча район башлыгы, район Советы рәисе Рамил Муллин 2020 елда районның социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре белән таныштырды. Ә нәтиҗәләр куанычлы. Хуҗалык эшчәнлеге алып бару өчен шактый катлаулы ел булуга карамастан, районыбыз иң югары трибуналардан сөйләрлек уңышларга иреште. Район башлыгы билгеләп үткәнчә, соңгы биш ел нәтиҗәләре буенча районда тулай продукциянең үсеш динамикасы 217 процент тәшкил иткән. Гомумән, тулай территориаль продуктның 58 проценты – авыл хуҗалыгына, 11 проценты сәнәгать тармагына туры килә. Узган ел 6 млрд 400 млн сумлык тулай территориаль продукт җитештерелгән. Сәнәгать җитештерүе индексы 135 процент тәшкил иткән. Бу исә республиканың социаль-икътисадый рейтингында, бер елда 26 позициягә күтәрелеп, унөченче урынны алырга мөмкинлек биргән. Авыл хуҗалыгы формированиеләре 2 млрд 500 млн сумлык продукция җитештергән. Узган ел белән чагыштырганда үсеш – 37 процент.

– Тармакның җитештерү-икътисад күрсәткечләре буенча район республика рейтингында уникенче урынга күтәрелде. Ә кош итен җитештерү буенча республикада җиденче урында торабыз, – диде Рамил Муллин.

Киләчәктә терлекчелек тармагында җитештерү күләме арту тармакның үсеш потенциалын тагын да күтәрер дип фаразлана. “Август-Агро” компаниясе төзегән сөтчелек комплексы да бу юнәлешкә уңай йогынты ясаячак.

– Тармакка инвестицияләр кертү дәвам итәчәк. 2021 ел ахырына Үрәзмәт комплексының тагын 1200 баш савым сыерына исәпләнгән икенче чиратын да файдалануга тапшыру күздә тотыла. Комплексны техника һәм җиһазлар белән тулыландыру, терлекләр өчен “яшел линия” алу да планлаштырыла, – диде “Август-Агро” идарәче компаниясенең башкарма директоры Ришат Закиров.

Район башлыгы соңгы елларда республика ярдәме белән башкарылган эшләрне дә барлады. Узган биш елда гына да социаль-инфраструктура объектларын төзекләндерүгә президент программалары һәм милли проектлар нигезендә 5 млрд 500 млн сум инвестиция җәлеп ителгән. Иң күләмле эшләр юллар төзелешенә туры килә. Соңгы биш елда гына да 3 млрд сумлык юл төзү-төзекләндерү эшләре башкарылган.

**(Ахыры 2 биттә).**

Хәбәрләр

**Бәйрәм белән!**

**Район башлыгы, район Советы рәисе Рамил Муллин Ватанны саклаучылар көне уңаеннан райондашларга котлау сүзләрен җиткерде. Анда мондый юллар бар:**

“Бу көнне без Кораллы Көчләрнең барлык буынын хөрмәтлибез. Алар Россия дәүләтенең тотрыклылыгы һәм иминлеге сагында тордылар һәм торалар. Без Бөек Ватан сугышы каһарманнарының батырлыгы белән горурланабыз, әфганчыларның чыдамлыгына, кайнар нокталарда илебезнең бөтенлеген саклаган солдат һәм офицерларның ныклыгына сокланабыз. Илебез тыныч, күк йөзебез аяз булсын!”

**Хезмәтләрен хөрмәтләп**

Район ветераннар советы рәисе **Низамов Илгиз Хафиз улы** Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе, һөнәри һәм иҗтимагый эшчәнлектә казанышларга ирешүе өчен “Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел” медале белән бүләкләнде.

Республиканың урман хуҗалыгын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен “Минзәлә урманчылыгы” дәүләт казна учреждениесенең Усы участок урманчылыгы участок урманчысы **Гыймранов Ринат Рәкыйп улына –** “Татарстан Республикасының атказанган урманчысы”,

“Мөслим картлар һәм инвалидлар интернат-йорты” дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры **Шакирҗанова Гөлнар Гарифҗан кызына** халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге казанышлары һәм намуслы хезмәте өчен – “Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре”,

район үзәк хастаханәсенең балалар табибы **Мөҗипова Резеда Әнәс кызына** халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары өчен “Татарстан Республикасының атказанган табибы” дигән мактаулы исем бирелде.

Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Демидов Рафаэль Тимофей улы** – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәгарифтәге казанышлары өчен”,

Мөслим сәнгать мәктәбенең халык уен кораллары бүлеге укытучысы **Салихҗанова Дилбәр Рифкать кызы** Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының “Мәдәнияттәге казанышлары өчен” билгесе белән бүләкләнде.

# Әфган утын кичкән Суворов

23 февраль – Ватанны саклаучылар көне. Батыр йөрәкле ир-егетләребез чит илләрдә иминлекне тәэмин итүдә дә үзләрен курку белмәс солдатлар итеп танытты.

Хәтер

**Лилия Шәймиева**

**Әфганстан сүзен ишетү белән аның йөрәгендә мәңге төзәлмәс яра сыкрап куя... Тау-кыялар арасыннан исән-имин кайтса да, утлы еллар вакыйгалары аның җанын гел бимазалап тора. Сүзебез Торыш авылыннан әфган сугышы ветераны Илшат Гәрәев турында.**

– Үзбәкстанда – Фирганә өлкәсенең Янги-Чек авылында туганмын. Ике яшем тулгач, әти белән әни, балаларын алып, Мөслим җирлегенә кайтып төпләнгән. Алты баланың бишенчесе идем мин. Иркәләнеп тә, эшләп тә үсәргә туры килде. Унсигезем тулгач, армия сафларына алдылар, – ди Илшат абый.


Куйбышев шәһәренең гомуми хәрби полкында төгәл бер ел хезмәт иткәч, Илшатны Әфганстанга җибәрәләр. Автовзводтан алар дүртәү китә. Аралырында Мари Бүләр егете Вячеслав Байгузин һәм Красноярдан Зөфәр Садретдинов та була.

– АН-22 самолеты белән Кабулга якын гына булган Баграм шәһәренә килеп төштек. Барлыгы 300 кеше идек. Бер көннән соң – Кабулга, аннары Джалалабад шәһәренә юл тоттык. Хәтерлим, гыйнвар ае иде. Безне юл буйларына сакка куйдылар, машиналар озатып йөрдек. Апрель аенда гына БТРлар килә башлады. Мине дә БТРга пулеметчы итеп куйдылар, – ди ветеран.

Ике тапкыр Термез шәһәренә чыга солдатлар. Бамьян шәһәренә барганда, көчле атышка туры килеп, чолганышка эләгәләр. Ике егет вафат була, тагын дүртесе каты яралана. Бәхеткә, Илшат камалыштан исән-имин чыга.

Әтисе һәм абыйсы сунарчы булган Илшат кечкенәдән корал белән идарә итәргә өйрәнеп үскән була. Сугышның үзәгенә килеп эләккәч, утлы коралны бик нык иплә кулланa белгән егетнең иңсәсендәге винтовкасы аерылмас дустына әверелә. Алты ай буе әти-әнисе дә, туганнары да Илшатның нинди мәхшәргә килеп эләккәнен белмиләр. Хәер, белсәләр дә нишли алалар иде соң?! Беркемнән сорамыйча башланган кирәксез сугыш бик күп аналарны вакытсыз картайтты, сабыйларны тартып алып, кара гүрләргә кертте...

– Иң истә калганы – сусызлык, такы-токы ашау. Коелар күп булса да, алардан су эчәргә ярамады. Душманнарның коелардагы суны агулап китү очраклары аз булмады. Шуның аркасында да сугышчан дусларны югалтырга туры килде. Әфганстан җирләреннән әйләнеп кайткач, әфганчы дусларны югалту тагын да авыр иkән. Туган якларга кайтып алты ай да үтмәде, табут белән күрше авыл егете Славикны алып кайттылар, – дип, күңел яраларын кузгатты Илшат абый. – Кичә генә бергә булган хезмәттәш дустыңның мәетен күрү, туган якларга кургаш табутлар озату, чүлләр кызуы, җилләр камчысы – болар беркайчан да онытылмас. Без Әфганга үләрбез дип бармаган идек...


Лилия Шәймиева фотосы.

Илшат Гәрәев, башка әфганчылар кебек, ул елларда күргән-кичергәннәре турында җәелеп китеп сөйләргә яратмый. Совет гаскәрләрен Әфганстан җиреннән чыгару көне якынлашканда хатирәләр кабат яңара, “бу авыр истәлекләр гомер буе озата барачак икән” дип, күңеленнән генә кабатлый ул...

Илшат абый хәләле Рәсимә апа белән ике бала үстергән, өч оныклары бар. Әфганчылар да, чордашлары да аңа исеме белән түгел, ә кушаматы белән дәшә. Суворов диләр аны... Мәктәп елларыннан ук укырга ятраткны, фәннәргә мәхәббәте, башлангыч хәрби әзерлек дәресләрен аеруча яратканы өчен бирелгән әлеге кушамат әнә шулай ничә еллар озатып йөри үзен.

# Әсгать Сәфәров: “Шәһәрләр дә көнләшерлек”

**Әлфинур Ногманова, Лилия Шәймиева**


**(Ахыры. Башы 1 биттә).**

Төзү-төзекләндерү эшләрен алып баруда җирле средстволарның да роле зур, әлбәттә. Аерым алганда, үзара салым программасының әһәмияте зур. Авыл җирлекләре территорияләрен төзекләндерү, парклар, балалар мәйданчыклары төзүдән тыш, 260 км озынлыкта юллар ремонтланган, күп санда күперләр төзекләндерелгән, 80 км озынлыкта су челтәрләре төзелгән һәм яңартылган, 3 меңгә якын светодиодлы яктырткычлар урнаштырылган h.б.

Рамил Муллин, мәгариф, мәдәният, спорт өлкәсендәге уңышларны бәян иткәннән соң, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлеккә тукталып, болай диде:

– Заман таләпләренә җавап бирүче ныклы база булдырдык. Ләкин бу өлкәдә хәл ителәсе проблемалар да бар әле. 1000 кешегә исәпләгәндә гомуми үлем очраклары республиканың уртача күрсәткеченнән шактый югары – 19,6. Балалар үлеме буенча хәл тагын да аяныччрак.

Сессия утырышында шулай ук район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Ренат Вәлиевнең, Мөслим урта мәктәбе директоры Илзир Мадьяровның өстәмә чыгышлары тыңланды.


Ринат Гыймранов бүләк ала./ РИММА АФЗАЛОВА ФОТОСЫ.

Йомгаклау сүзе белән чыккан Әсгать Сәфәров районның социаль-икътисадый күрсәткечләр буенча күп позицияләрдә республика рейтингында алдагы урыннарга күтәрелә баруын билгеләде. Соңгы елларда районда республика программалары нигезендә Европа стандартлары югарылыгында алып барылган төзү-яңарту эшләренә югары бәя бирде.

– Мәгариф учреждениеләрендә белем һәм тәрбия бирүдә кулланылучы инновацион технологияләргә, заманча алымнарга республика районнары гына түгел, шәһәрләр дә көнләшерлек, – диде ул.

Аннары Президент аппараты җитәкчесе республика һәм районыбызның халык хуҗалыгы тармаклары үсешенә зур өлеш керткән райондашларыбызга хөкүмәт бүләкләрен тапшырды.

Әсгать Сәфәров ул көнне капиталь ремонт үткәрелгән балалар сәнгать мәктәбен ачу тантанасында да катнашты. Чарага ТР Мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов, оешма-предприятие җитәкчеләре, авыл җирлекләре башлыклары да килгән иде. Кунаклар мәктәпнең алдынгы укучылары, фольклор, вокаль ансамбльләр, халык һәм тынлы уен кораллары оркестры чыгышлары белән таныштылар. Рәсем сәнгате бүлеге укучылары әзерләгән күргәзмәне карадылар. Мәктәп белән танышканнан соң, Әсгать Сәфәров, башкарылган ремонт эшенә югары бәя бирде:

– Бирелдә илебезнең лаеклы гражданнары тәрбияләнә. Шушындый зәвыклы, бөтен уңайлыклары булган, уку өчен бөтен шартлар тудырылган мәктәпне сафка бастырган төзүчеләргә рәхмәттән башка сүз юк. Сәнгать мәктәбендә белем алган егет-кызлар киләчәктә республика һәм ил күләмендә танылган йолдызлар булып балкырлар әле, – диде Әсгать Сәфәров һәм, очрашу истәлеге итеп, мәктәпкә картина бүләк итте.

Президент ярдәмчесе башка объектлар, иҗтимгый киңлекләр белән дә танышты. “Кояшлы Ык” ял зонасында зәвык белән башкарылган эшләр, “Агромастер” җитештерү компаниясендә эшләп чыгарылучы авыл хуҗалыгы техникасы да кунакларда зур кызыксыну уятты. “Мөслим халкының, шәһәрләрдән калышмыйча, лаеклы тормыш алып баруы – аның хезмәт сөюендә”, – дип билгеләп үтте Ә. Сәфәров.

Мәгариф

# Әйдаманнар алга әйди

Балаларны яраткан, тирә-юньдәге үзгәрешләргә битараф булмаган, һәрвакыт яңалыкка, камиллеккә омтылган егет-кызлар, әйдаманнар буларак, үзләре артыннан күпләрне иярттергә сәләтле.

**Балалар иҗтимагый хәрәкәтенең ролен күтәрү, отряд вожатыйларының дәрәҗәсен арттыру һәм укытучы һөнәренә кызыксыну уяту максатында районда ел саен "Искиткеч вожатый" конкурсы үткәрелә.**

Мәктәптән тыш эшләр үзәге хезмәткәрләре тарафыннан конкурсның муниципаль туры уздырылды. Анда мәктәпләрдә узган сайлап алу турында җиңү яулаган унөч әйдаман катнашты. Конкурска гел кызлар гына килгән иде, дисәк, бик үк дөрес булмас. Сал. Мухан мәктәбеннән Евгений Шитюк дигән егетебез икенче тапкыр инде үзен сынап карады. Алга китеп шунысын да әйтәсе килә: Женя "Иң өлгер, иң җитез әйдаман" номинациясендә җиңүче булды.

Ярыш дүрт этаптан торды. Әйдаманнар иң элек үзләре белән таныштыручы презентация тәкъдим иттеләр. Интеллектуаль бәйгедә, педагогик ситуацияләрдә көч сынаштылар, лайфхак күрсәттеләр. Әйтергә кирәк, әйдаманнар бәйгегә ныклап әзерләнгән. Һәркайсы сынауларны уңышлы узып, сорауларга иҗади якын килеп җавап бирде, сәләтосталылыкларын күрсәтте.

Жюри әгъзалары һәр чыгышны 5 баллы система белән бәяләде. Бәйге нәтиҗәләре буенча Г. Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбенең 10 класс укучысы Айсылу Әсадуллина (җитәкчесе – Г. Мәүлиева) өченче урынга лаек булды. Мари Бүләр мәктәбеннән Зәринә Мирсалихова (җитәкчесе – Л. Хәсәнова) икенче урынны яулады. Гимназиядән Эльвина Хафизова (җитәкчесе – Л. Солтанова), барлык этапларны уңышлы узып, иң күп балл җыйды һәм бәйгенең җиңүчесе булды. Эльвина, Мөслим данын яклап, республика этабында чыгыш ясаячак. Конкурста катнашкан һәр әйдаман төрле номинацияләрдә җиңүче булды. Аларга район мәгариф идарәсенең, мәктәптән тыш эшләр үзәгенең Мактау грамоталары тапшырылды.

Егет-кызларыбызга киләчәктә дә зур уңышлар телибез. Бүген үзләрен укытучыларролендә сынаган әйдаманнар киләчәктә хезмәт юлларын мәгариф тармагы белән бәйләр һәм җирлегебез мәктәпләренә остазларына алмаш булып кайтырлар, дигән өметтә калабыз.



Менә алар – әйдаманнар./ ФОТО – МӘКТӘПТӘН ТЫШ ЭШЛӘР ҮЗӘГЕ АРХИВЫННАН.

**Наилә Сәлахова,**
**мәктәптән тыш эшләр үзәге методисты.**

# Кинога йөрисезме?

Фикер

**Хәзер кинофильмнарны телевизордан гына түгел, телефоннан да карап була.**

Ә шулай да саф һава сулый-сулый кинотеатрга баруга, киноны иптәшләрең белән бергә карауга җитәме соң?! Кинофильмнан алган тәэсирләргә дусларың белән аралашудан алган тәэсирләр дә килеп кушылгач, кәефең тагы да күтәрелә.

Балачактан ук кино караргә йөрдек. Телевизорны безнең урамда яшәүчеләрдән беренчеләрдән булып карый башласак та, киноны клубка барып карау кызыграк иде. Ул чакта Мөслимдә сеанслар көнгә дүрт тапкыр була иде. Әйбәт кино дисәләр, билет алу өчен касса тәрәзәсенә якын килерлек булмый иде. Бер тапкыр (башлангычта укыганда бугай) күрше кызы белән сәгать дүрттәге сеанска кердек. Чыгуыбызга аның апасы: "Әйдә минем белән дә карагыз инде", – дигәч, билет алып, тагын кереп киттек. Өйгә кайткач и орыштылар инде үземне. Биюче кызлар турында иде бугай фильм. Исеме "Девичья весна" идеме шунда, онытылган инде.

Тагын бер кызык истә калган. Кинога барышлый акчабызны юлда очраган машина тәгәрмәче астына ыргытып уйныйбыз. Ул вакытта урамда машиналар күп йөрмәсә дә, очрап торган инде. Каршы килгән машина тәгәрмәче астына 10 тиенемне аттым. Ә машина узып киткәч, акчам табылмады. Күрәсең, ябышып киткәндер. Кинога кердем микән, хәтерләмим. Ә минә 10 тиен бала-чага өчен зур акча иде, чөнки аңа ике тапкыр кино карап була иде.

Мәктәп, студент елларында, яшь чакта да йөрдек кинотеатрларга. Студент чакта, лекцияләргә кермичә, кинога киткән чаклар да булды инде. Хәзер, олыгайгач та, барасы килеп куя һәм елга бер булса да барам кинотеатрга: телевизордан "кинотеатрларда гына булачак" дип рекламаланган фильмнары карыйсы килә бит. Башкалар да минем кебек елга бер генә йөри микән, чөнки зал буш була. Инде ничә тапкыр үзебез генә карап чыккан булды. Кызык икән хәзер кинотеатрда: билетны кафедан аласы. Безне, "Көнбагышлары юк микән?" дип, ишек төбендә тикшереп керткән чаклар да булды, ә хәзер алып кергән ашамлыгыңны куяр өчен урындыкка җайланмага кадәр көйләп куелган. Шунысы бар: тавышы гына бик каты. Әллә без – картларга шулай тоела гына микән? Ә сезнең кинога барганыгыз бармы?




Фото – Әмәкәй мәктәбе архивыннан.

**Миләүшә Гарипова.**

# Ташламалар бар

Игътибар!

**Мөнирә Арсланова**

**Пандемия сәбәпле оешмалар, шәхси эшмәкәрләр салымнар түләүдә берәр төрле ташламалардан файдалана аламы? Бу хакта салым хезмәтенең 11 санлы районара инспекциясенең район бүлеге җитәкчесе Гөлсем Миңнуллина белән сөйләштек.**

**– 2020 ел өчен оешмалар нинди ташламалардан файдалана ала?**

– 2020 ел өчен отчет чорыннан башлап, оешмалар транспорт һәм җир салымнары буенча салым декларацияләре тапшырмый. Бу "Россия Федерациясе Салым кодексының икенче бүлегенә һәм "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче бүлекләренә һәм Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы башка закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль законның 9 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында"гы 63-ФЗ санлы 2019нчы елның 15 апрелендәге Федераль закон нигезендә эшләнә. Бу ташламадан файдалану өчен транспорт яисә җир салымнары буенча ташламаларга хокуклы оешмалар гариза тапшырырга тиеш. Аның формасы Россия Федераль салым хезмәте боерыгы белән расланган. Гаризаны карап тикшергәннән соң салым органы салым ташламасын бирү яисә бирмәү турында белдерү җибәрәчәк.

**– Гаризаны кайчанга кадәр тапшырырга була?**

– Ташлама турында гариза тапшыруның вакыты билгеләнмәсә дә, аны быелның беренче кварталында тапшырырга тәкъдим итела.

**– Эшмәкәрләргә карата нинди ташламалар каралган?**

– Эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылучы (файдалану өчен билгеләнгән) объектларга карата 2020нче елның 1 апреленнән 2020нче елның 30 июненә кадәр шәхси эшмәкәрләрне милек, транспорт һәм җир салымнарын түләүдән азат итү карала. Бу хакта "Россия Федерациясе Салым кодексының икенче бүлегенә үзгәрешләр кертү турында"гы 172-ФЗ санлы Федераль законда (08.06.2020) бәян ителә. Әлеге ташламадан файдалану өчен шәхси эшмәкәр салым органына гариза һәм ташламаны раслаучы документларын тапшыра ала.



# Котлыйбыз!

Иске Карамалы авылында яшәүче кадерле әтиебез **Муллашов Рафил Муллахан улына** 19 февральдә – 64 яшь, әниебез **Муллашова Дамира Фәнүз кызына** 20 февральдә 60 яшь тула.

Кадерле әти-әниебез! Сезне ихлас күңелдән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә ныклы сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә иминлеге, шатлык-куанычлар, тулы мул тормыш, бергәбергәзгә терәк булып озак яшәвегезне телибез. Сез безнең ныклы таянычыбыз, ышанычлы терәгебез. Әтиәни, барысы өчен дә бик зур рәхмәт сезгә!

*Изге теләкләрдән,*
*назлы сүздән башка*
*Табып булмый затлы бүләкне.*
*Безнең өчен бик тә кадерле сез,*
*Бик тә якын, бик тә кирәкле.*
*Әни бит ул өйнең җылысы,*
*Әти – дөнья терәге.*
*Әни белән әти бергә булса,*
*Тыныч була бала йөрәге.*

**Иң изге теләкләр белән**
**Айдар-Айгөл, Азилә,**
**Рамазан.**

**ГКУ «Центр занятости населения Муслюмовского района»** объявляет набор на 2021 год из числа безработных граждан на профессиональное обучение и дополнительное профессиональное образование.

Обучение проводится по профессиям:

**Бухгалтер (1С: Предприятие) срок обучения 1,5-3 мес.**
**Закройщик (швея) – 2-3 мес.**
**Кондитер – 1,5-3 мес.**
**Электрогазосварщик – 3-6 мес.**
**Водитель категории «Е» – 3 мес.**

Желающих приглашаем по адресу с. Муслюмово, ул. Пушкина, д.47.
**Справки по тел.: 8(85556) 2-48-34.** Реклама

**27 февраля на территории рынка с 8.00 до 13.00**
**ПОСТЕЛЬНОЕ БЕЛЬЕ от интернет-магазина «СОЛОВИЯ» (г.Иваново) РАСПРОДАЖА**

***Комплект***
*1,5 сп. бязь Лайт от 450 р.*
*1,5 сп. бязь от 600 р.*
*1,5 сп. поплин от 700 р.*
*2,0 сп, евро, семейные.*
***Пододеяльник***
*1,5 сп. бязь Лайт от 230 р.*
*1,5 сп. бязь от 310 р.*

***Простыня***
*1,5 сп. бязь Лайт от 120 р.*
*1,5 сп. бязь от 160 р.*
*2,0 сп бязь ГОСТ от 230 р.*
***Наволочки***
*70/70 бязь от 60 р.*
*70/70 бязь ГОСТ от 75 р.*
*50*70, 60*60 от 50 р.*

***Подушки от 200 р. Одеяла от 400 р. Полотенца от 25 р.***
***ТОЛЬКО 100% ХЛОПОК!!!*** Реклама

# Туган нигез

## Хәтер-хатирә

**Бу – минем туып-үскән нигезем... Бу – минем туган авыл! Моннан бик күп еллар элек әтиебез күрше Атлас авылыннан әниебезне шушы нигезгә алып кайткан.**



Фото – Нәҗия Исәнбаеваның гаилә архивыннан.

61 ел элек шушы салам түбәле, такта коймалы йортта яңа гаилә барлыкка килгән. Бик тату, эшчән, тырыш гаилә булган ул. Шау-гөр килеп балалар үскән, ихата ныгытылган, абзар-кура торгызылган, яңа йорт төзелгән. Мүк аралары балчык белән сылап җылытылган, ике генә тәрәзәле бәләкәй генә шушы йортка карыйм да, күңелемдә әйтеп-сөйләп бетергесез хатирәләр яңара, хисләр өермәсе кузгала.

Җитез хәрәкәтле, сабыр холыклы, буе орчык кадәр генә булган әбекәем күз алдыма килә. Бер ярдәмчесез калып, бик күп авырлыклар күрсә дә, рухы сынмады, тормышны яратуы кимемәде. Бер-бер артлы 9 баласын югалтканнан соң, бердәнбер таянычы, өмете булган әтиебез тәрбиясендә яшәп, 83 яшендә тыныч кына бакыйлыкка күчте.

Нәкъ менә шушы нигездә биш бала үстек без, шушында тәпи атлап киттек. Олы тормыш юлларына да шушы ихатадан, шушы капкаларны зур итеп ачып, ныклы адымнар белән чыгып киттек.

Безне күз карасыдай кадерләп үстергән әбиебез, тормышка аек акыл белән караргa өйрәткән кадерле әтиебез, сабыр холыклы, мөлаем йөзле газиз әниебез! Соңгы көннәребезгә кадәр сезнең йөз аклыкларыгыз булып яши алсак, без бик бәхетле булыр идек...

**Нәҗия Исәнбаева.**
**Мөслим.**

**Натяжные потолки.**
**Встроенные шкафы-купе.**
**Жалюзи.** **Т.8-927-489-51-08.** Реклама

***СЫЕР, УГЕЗ ИТЕ.***
**Т.8-987-035-98-01,**
**8-927-301-01-34.** Реклама

**“ДОМ КРОВЛИ”**
**Профнастил по оптовым ценам**
**Пластиковые окна**
**и алюминиевые двери,**
**АВТОМАТИЧЕСКИЕ ВОРОТА**
с.Муслюмово, ул.Урожайная, д.5
**Т.8-960-087-66-96.** Реклама

**ГКУ «Центр занятости населения Муслюмовского района»** проводит рассмотрение бизнес-планов для оказания государственной поддержки безработным гражданам, желающим организовать предпринимательскую деятельность в 2021 году.
За справками можно обращаться по **тел. 2-48-34 и 2-49-50.** Реклама

## Реклама

**Сатыла**

**терлек**

▶ **Бозаулар.** Т.8-987-272-38-33.
▶ **Бозаулар** сатыла. Т.8-937-777-20-88, 8-960-079-78-44.

**төзелеш материаллары**

▶ **Окна. Ворота.** Двери. Балконы. Т.8-937-774-37-37.

**төрлесеннән**

▶ **Көрпә, фураж.** Т.8-962-566-39-05.

**Хезмәт күрсәтәбез**

▶ **Ремонт холодильников.** Т.8-951-067-74-13.
▶ **Ремонт холодильников,** стиральных машин. Т.8-917-895-15-54, 8-927-476-86-86.
▶ **Ремонт, настройка телевизоров.** Т.8-950-324-08-91.
▶ **Грузоперевозки “Газель”.** 5 м. Т.8-977-056-24-16.

**ПЛАСТИК ТӘРӘЗӘЛӘР ИШЕКЛӘР**
**Т.8-953-480-00-75**
**Заводта ясала** Реклама

▶ **Натяжные потолки.** Т.8-939-311-71-14.
▶ **Спутниковые антенны МТС.** Телекарта, интернет 4G, обмен. Т.8-960-060-95-95.
▶ **Йомшак мебель тышлыйбыз.** Т.8-906-117-07-14.
▶ **Натяжные потолки.** Фаиль. Т.8-987-210-89-88.

**Сатып алам**

▶ **Куплю крупный картофель.** Т.8-963-893-55-63.
▶ **Сыер, үгез** – итләтә, терелэй (төрле хәлдә). Т.8-987-135-03-47, 8-927-940-31-01.
▶ **Үгез, сыер.** Т.8-927-966-55-53.
▶ **Терелэй сыер,** үгез, таналар (төрлесеннән). Кыйммәт. Т.8-927-923-03-38.
▶ **Итләтә һәм терелэй мал.** Т.8-917-435-41-04.

## Файдалы киңәш

**Калла**

Бу гөлне бик тиз бәхәскә кереп, кызып китүчән балалары булган өй һәм фатирларда үстерү яхшы. Ул шулай ук күрү, ишетү, тоемлау, тәм һәм ис сизү органнарының эшчәнлекләрен дә саклый. Хәтта балаларның эчәклекләр белән бәйле булган чирләрен дәваларга да сәләтле, ди белгечләр.

**Цикламен**

Киребеткән, үҗәт балалары булган әниләргә өйләрендә цикламен гөлен үстерергә киңәш ителә. Чөнки бу гөл үскән бүлмәләрдә балалар үзләрен гадәттәгедән тынычрак тотачак. Алар үзләренә берәр шөгыль яки уен табып, шуның белән мәшгуль булачаклар, рольле уеннарга өстенлек бирә башлаячаклар. Мәктәпләрдә музыка һәм рәсем сәнгате кабинетларының тәрәзә төпләрендә күпләп цикламен үстерү иҗадилыкны арттырачак, ди флористлар.

**Извещение о необходимости согласования проекта межевания земельных участков**

Кадастровым инженером Валиевым Фанилем Султановичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера №16-10-54, 423350, РТ, Сармановский муниципальный район, с.Сарманово, ул.Ленина, д.26, sar-zem@mail.ru, тел.8-917-396-07-69) подготовлен проект межевания земельного участка общей площадью 4,2 га, выделяемого в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:29:000000:1207, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Муслюмовский муниципальный район, на землепользовании ООО ФХ "Сафар".

Заказчиком работ является Нурмухаметов Ильмир Мирзамухаметович, проживающий по адресу: РТ, Муслюмовский муниципальный район, с.Муслюмово, ул.Искандерова, д.15, тел.: 89172883508. С проектом межевания земельного участка можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч. по адресу: РТ, Сармановский муниципальный район, с.Сарманово, ул.Ленина, д.26, 2 этаж, ООО «ГеоСфера».

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельных долей земельного участка и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются в течение 30 (тридцати) дней со дня опубликования данного извещения. *(* п.8, п.11 ст.13.1 Федерального закона от 24.07.2002 г. №101-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения»). Реклама

**Извещение о необходимости согласования проекта межевания земельных участков**

Кадастровым инженером Валиевым Фанилем Султановичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера №16-10-54, 423350, РТ, Сармановский муниципальный район, с.Сарманово, ул.Ленина, д.26, sar-zem@ mail.ru, тел.8-917-396-07-69) подготовлен проект межевания земельного участка общей площадью 12 га, выделяемого из земельного участка с кадастровым номером 16:29:000000:330, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Муслюмовский муниципальный район, Михайловское сельское поселение, тер. Паевые земли, з/у 2.

Заказчиком работ является Ахметханов Кутдус Харрасович, адрес: РТ, г.Набережные Челны, прос.Сююмбике, д.17, кв.356, (тел: 89274938928).

С проектом межевания земельного участка можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч. по адресу: РТ, Сармановский муниципальный район, с.Сарманово, ул.Ленина, д.26, 2 этаж, ООО «ГеоСфера», т.2-57-86.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельных долей земельного участка и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются в течение 30 (тридцати) дней со дня опубликования данного извещения в ООО «ГеоСфера». *(* п.8, п.11 ст.13.1 Федерального закона от 24.07.2002 г. №101-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения»). Реклама

Мөслим лицее коллективы, профсоюз комитеты, лаеклы ялдагы **Дәүләтшина Флүрә Хәбиб кызы** вафат булу сәбәпле, оныкларының, якыннарының тирән кайгысын уртаклаша. Бу кайгыны кичерүдә сабырлык тели.

Гамәлгә куючы: “ТАТМЕДИА” АҖ. www.muslumirc.ru Реклама хезмәте телефоны: (85556) 2-43-05.

Авыл утлары
Мөслим районы газетасы
“ТАТМЕДИА” АҖ филиалы директоры – баш редактор **Р. Р. Афзалова.** Тел.: 2-55-00.

**Редакция адресы:** 423970, Татарстан, Мөслим районы, Мөслим авылы, Пушкин ур., 43.
**Электрон адрес:** muslimau@rambler.ru
**Телефоннар:** бухгалтерия – 2-39-76, реклама, заказлар – 2-43-05.
**Газетаның оештыручысы һәм нәшире:** "ТАТМЕДИА" АҖ. 420097, Казан шәһәре, Академическая ур., 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникация сферасында күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсендә ПИ №ТУ16-01027 номерлы таныклык белән 2013 нче елның 16 маенда теркәлде.
Газета “Глагол” ҖЧҖ басылды.
Адресы: 423800, ТР, Яр Чаллы шәһәре, Әлмәт тракты, 10 йорт, 3 бина.
Басарга кул куелды 18.02.2021, график буенча – 19.00, фактта – 16.19.
«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

**Тираж – 2516 данә.**

Редакция фикере һәрвакыт та авторлар фикере белән аваздаш булмаска мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булу мөмкинлеге юк.
**Кулъязмаларга бәяләмә язылмый һәм алар кире кайтарылмый.**
Реклама-игъланнардагы мәгълүматның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

© Материаллар редакциянең язма рөхсәте белән генә күчереп бастырылырга мөмкин.

Газета татар телендә атнага ике тапкыр – чәршәмбе һәм җомга көннәрендә, рус телендә атнага бер тапкыр – җомга көнне чыга.
Заказ №244.
Язылу индексы: – П9418.
Бәясе ирекле.
16+